**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 ноябрендәге 4127 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 2520 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезләмәләренә туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 2520 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«8. Резерв фонды акчалары бүлеп бирелә торган Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, алар карамагындагы учреждениеләр акчаларны максатчан файдалану өчен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә, хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, кушымтада китерелгән форма буенча әлеге акчалардан файдалану турында хисап тапшыра»;

1.2. 9 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. 10 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«10. Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы карарлары Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе белән мәҗбүри килештерелергә тиеш».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы – урынбасар** **И.В.Куляжев**